ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Телерадиотапшырулар буенча федераль конкурс комиссиясендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкиле турында

Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең 2012 елның 25 маендагы 522 номерлы боерыгы белән расланган Телерадиотапшырулар буенча федераль конкурс комиссиясе турындагы нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Телерадиотапшырулар буенча федераль конкурс комиссиясендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкиле итеп Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Зарипов Айрат Ринат улын билгеләп куярга.
2. «Телерадиотапшырулар буенча федераль конкурс комиссиясендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкиле турында» 2017 елның 16 февралендәге 1630-V ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарының үз көчен югалтуын танырга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2019 елның 25 сентябре
№ 83-VI ДС